# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕ МӘҢГЕЛЕК



Презентацияне
Казан шәһәре 99нчы урта мәктәбенең
11 а сыйныфы укучысы
Саляхова Гөлнур
әзерләде



Җырларын ятлап

күңелдән,

Талантына таң калып,

Бөек җырчысы янына

Тукайга килә халык...

# ТАТАРСТАНДА ТУКАЙ ЕЛЫ.

Бөек татар шагыйре Г. Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан 2011ел Татарстан Республикасында Тукай елы дип игълан ителгән иде.

Ә быел, 2016 елда сөекле шагыйребезнең 130-еллык юбилеен билгеләп үтәбез



# Тукайга килә халык

Һәр елны 26 нчы апрель көнне Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры янындагы Тукай һәйкәле янында Шигырь бәйрәме үтә. Бу бәйрәмдә Тукай исемендәге премия лауреатларының исемнәре атала.

# Тукай бүләге бирелү хакында



Әдәбият, рәсем, музыка сәнгате һәм архитектура өлкәсе үсешенә аеруча зур өлеш керткән кешеләргә 1958 нче елның апреленнән Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелә башлый.

Тукай премиясенең беренче лауреатлары:

Ф.Яруллин – композитор;
Н.Җиһанов – композитор;
Ә.Фәйзи – язучы һ.б.

# Казанда Тукай музее




Тукай урамы 74 нче йортта 1986 нчы елның 11 нче июнендә Г.Тукай музее ачыла.

# Тукайның шәхси әйберләре




Музейда Тукайның юл сумкасы саклана



Тукай музееннан экспозиция

# Кырлайдагы Тукай музееның тышкы күренеше





**Кырлайда Г.Тукайның мемориаль музее эшләп килә.Музей каршында Тукайга куелган һәйкәл урын алган. (авторы Бакый Урманче,1976 ел)**

# Кушлавычта Тукай музее



Шагыйрьнең туган авылында музей-йорт эшләп килә, музей каршында шагыйрьнең бюсты бар.

# Университет бинасында Тукай бүлмәсе



Бу бүлмә элеккеге ТДГПУ бинасында 2010елның 24 нче апрелендә ачыла

# Тукай исеме мәңгелек

**Казанда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармония концерт залы**



# Һәйкәлләре




1958 нче елда башкалабызның Тукай мәйданында куелган һәйкәлнең авторлары: скульптор – С.С.Ахун, Л.Е.Кербель, М.М. Писаревский, архитектор – Л.Н. Павлов.




Казанда Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры бинасы янында Тукай һәйкәле. (Скульптор – Шулин Е.И.)

# Петербургта Тукайга куелган һәйкәл



# Уральск шәһәре дә Тукай рухын саклый



# Арчада да шагыйрь белән бәйле урыннар бар



Арчадагы педагогия колледжы шагыйрь исемен йөртә

# Тукай исемен теплоходка да биргәннәр



Бу 150 кеше сыйдырышлы круиз теплоходы Идел елгасы буйлап сәяхәт итә. Ул 1962 нче елда Венгриядә төзелгән.

# Казанда Г.Тукай исемендәге метро станциясе



Станция шагыйрьнең әкиятләренә, шигырьләренә багышлап ясалган иллюстрацияләр белән бизәлгән

# Башкалабызда шагыйрь исемен йөртә торган җыр һәм бию ансамбле дә бар



# Тукай тормышын өйрәнү




Шагыйрь иҗатын өйрәнү һаман дәвам итә. Тормышы һәм иҗаты хакындагы китаплар татар һәм рус телләрендә генә түгел, чит телләрдә дә басыла. Әлеге басма Тукайның яшерен сөюе хакында.

# Тукай сәхнәдә

Күп кенә язучыларыбыз, шагыйрьләребез үзләренең әсәрләрендә Г. Тукай образына мөрәҗәгать итә. Ә. Фәйзинең “Тукай” традегиясе, Т. Миңнуллинның “Без китәбез, сез каласыз”, Р.Ишморатның “И мөкатдәс моңлы сазым” драмалары озак еллар сәхнәдән төшмәде. И.Нуруллин , Р. Батулла , Р. Зәйдуллалар да әсәрләрендә шагыйрь образын сурәтләделәр.

Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшьләр театры шагыйрьгә багышланган «Печән базары» спектаклен сәхнәләштерде.

# Тукай геройлары сәнгатьтә



“Шүрәле” балеты Мариинск театрында да куела.

# Рәссамнарның Тукайны күзаллавы

Дистәләрчә рәссамнар үз иҗатларында шагыйрь образын гәүдәләндерделәр. Болар арасында Х. Якупов, Л. Фәттахов, В. Федоров, Е. Симбирин, Х. М. Казаков, Н. Рәхимов исемнәрен атарга мөмкин.




**В.Федоровның**

**“Тукайның Өчиледән Кырлайга килүе” картинасы. 1975 ел.**



Х. Казаковның “Бәләкәй Тукай” картинасы. 1958 ел.



Е. Симбиринның “Шагыйрь Г.Тукай” картинасы. 1976 ел.

# Тукай геройлары мультфильмнарда

Г. Тукайның 125 еллык юбилее уңаеннан шигырь геройларына нигезләнеп татарча мультфильмнар төшерделәр. «Бала белән күбәләк», «Кәҗә белән сарык», «Ялкау маэмай», «Кызыклы шәкерт», «Кисекбаш», «Туган тел», «Тукай», «Ай һәм Кояш», «Кышкы кич», «Шаян песи», «Ак бабай», «Иртә», «Эш беткәч уйнарга ярый» - менә шундыйлардан.

# Мультфильмнардан күренешләр







# Тукай исемен бирү дәвам итә

- Тукай исеме белән бәйле урыннар, үткәрелә торган чаралар әле моның белән генә чикләнми. Казан шәһәрендә, Уфада, Уральскида,Алабугада, Арчада урамнар аның исемен йөртә. Республикабызда Тукай районы бар, Тукай-Кырлай дигән авыл бар. Мәктәпләрдә балалар оешмалары шагыйребез исемен йөртә. Республикада февраль-апрель айларында Тукай укулары үткәрелә. Мәскәүдә, А.С.Пушкин исемендәге сәнгать музеенда, Тукай истәлегенә күргәзмә оештырылды. Якын көннәрдә илебез башкаласы Мәскәүдә бөек шагыйребезгә һәйкәл куелачак.

# Чәчәкләр китерегез Тукайга.

Х.Туфан

Әйләнәндә — гөлләр...
Сүзен гүя
Шулар аша әйтә күңелләр:
— Туган көнең белән! — дигән сыман
Елмаялар кебек бу гөлләр.

Килә, килә... Язлар саен сиңа
Илең килә туган көнеңдә,
Бетми торган гомерен кушкан сыман
Синең бөек, кыска гомергә.

Ераклардан, йөзләп сукмаклардан
Килеп меңнәр һәйкәл
каршына,
Еллар саен арта бара торган
Сәламнәрен сиңа тапшыра…